| | |
|---|---|
| ГЛАВА ХОЗЕСАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13 ноябрь 2023 ел Хужа Хәсән авылы №1

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Хужа Хәсән авыл
җирлегенең Хужа Хәсән торак пунктында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хужа Хәсән авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2023 елның 22 ноябрenә 11 сәг 00 минутка Хужа Хәсән ав., Ольга Данилова ур., 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан Хужа Хәсән авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хужа Хәсән авыл җирлегенең Хужа Хәсән торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын*** билгеләргә.

2. 2023 елның 25 ноябрenә 11 сәг 00 минутка Хужа Хәсән ав., Ольга Данилова ур., 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан Хужа Хәсән авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хужа Хәсән авыл җирлегенең Хужа Хәсән торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.

3. 2023 елның 27 ноябрenә 14 сәг 30 минутка Хужа Хәсән ав.,. Мәктәп ур, 23 йорт адресы буенча урнашкан Хужа Хәсән урта гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хужа Хәсән авыл җирлегенең Хужа Хәсән торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***өченче этабын*** билгеләргә.

4. 2023 елның 28 ноябрenә 13 сәг 00 минутка Хужа Хәсән ав., Ольга Данилова ур., 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан Хужа Хәсән авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы

Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Хуҗа Хәсән торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Хуҗа Хәсән авыл территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- территорияләрне торак пунктның рөхсәтсез чүплекләреннән чистарту;
- материаллар сатып алып су башнясын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү;
- су челтәрләрен ремонтлау, материаллар сатып алу;
- материаллар сатып алып юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын карап тору;
- зират территориясен саклау, төзекләндерү һәм ремонтлау, материаллар сатып алу;.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башлыгы С.П.Матвеева